БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ

ВСЕМИРНЫЙ ФОРУМ ТАТАРСКОЙ МОЛОДЕЖИ
THE WORLD FORUM OF TATAR YOUTH

420066, г. Казань, К.Маркса, 38/5
тел. (843) 2997717, факс 264-63-37
e-mail: tatforum2020@gmail.com
Исх.№ 644от 24.03.2023

Актаныш муниципаль
районы башлыгы

Л.Р. ЗАРИПОВКА

Республикакүләм «Мин татарча сөйләшәм»
акциясенең Мәктәпләр бәйгесе турында

Хөрмәтле Ленар Рафак улы!

26 апрельдә, бөек татар шагыйре Габдулла Тукайны искә алу көнендә, 2005 елдан алып Бөтендөнья татар яшьләре форумы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы, Казан шәһәренең Башкарма комитеты белән берлектә «Мин татарча сөйләшәм» республикакүләм акциясен үткәрә. Әлеге акция кысаларында Татарстан Республикасы мәктәпләре арасында татар телен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә юнәлтелгән бәйге үткәрелә. Бәйгедә җиңгән 20 команда алга таба «Kazan Quest» уенына чакырыла.

«Kazan Quest» - 2023 елның 23 апрелендә Бөтендөнья татар яшьләре форумы Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе, Бөтендөнья татар конгрессы ярдәмендә үткәрелә торган татар телендә квест-уен.

Бәйгенең биремнәре нигезләмәдә язылган. Бәйгедә катнашу өчен https://forms.gle/dfbpVZr3tSy4556i8 сылтамасы аша кереп, **9 нчы апрельгә** кадәр заявканы тутырырга һәм эшләнгән биремнәрен беркетеп җибәрергә кирәк. Уенда 7-11 сыйныф укучылары катнаша ала. Мәктәптән бер команда чакырыла: 7 укучы һәм 1 куратор.

Хөрмәтле Ленар Рафак улы! Сезнең район мәктәпләрен бәйгедә катнашырга җәлеп итүдә ярдәм күрсәтүегезне сорыйбыз. Шулай ук районнан җиңүче мәктәп булса, «Kazan Quest» уенында катнашыр өчен Казанга кадәр транспорт белән тәэмин итүегезне сорыйбыз.

Элемтәләр өчен мәгълүмат: tatdozor@gmail.com, 236-49-66.

Бәйгенең нигезләмәсе кушымтада.

Ихтирам белән,
Бөтендөнья татар
яшьләре форумы рәисе Л.Р.Мөслимова

Башкаручы:
Ләйсән Фәхриева
+7 (939) 339 64-42